ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 126-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Һ. Галиев, Р.Г. Хөсәенов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 126-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 27 ноябре
№ 465-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
М.Һ. Галиев, Р.Г. Хөсәенов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (2020 елның 19 ноябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 12; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешмага Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә субсидия рәвешендә һәм (яисә) салымнар һәм җыемнар хакындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнгән салымны кайтару рәвешендә чыгымнарны каплауны (әгәр капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү Россия Федерациясе белән төзелгән булса) күздә тоткан дәүләт ярдәме чарасы түбәндәге чыгымнарга бирелергә мөмкин:»;

2) $1^1$ өлештә:

а) «, шул исәптән» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) «дәүләт ярдәме чаралары» сүзләреннән соң «,әгәр федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарларында һәм (яисә) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 241 статьясындагы 15 пункты нигезендә чыгымнарны Россия

Федерациясе бюджет законнары нигезендә субсидия рәвешендә каплаганда башкасы каралмаган булса,» сүзләрен өстәргә;

3) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру хакындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын башкаручы оешма әлеге статьяның 1 өлешендә бәян ителгән дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү рәвешен (рәвешләрен) сайлый һәм аны (аларны) әлеге статьяның 5 өлешендәге 5 пунктында каралган чыгымнарны каплау күләмен исәпләүдә күрсәтә.»;

4) $4^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$4^1$. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән субсидия һәм түләнгән салымны кайтару «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законның 15 статьясындагы $8^1$ һәм $8^2$ өлешләре нигезендә бирелә.»;

5) 5 өлешнең 7 пунктында «Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә бирелгән булса» сүзләрен «бирелгән булса. Үзләренә карата чыгымнар әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 – 3 пунктлары нигезендә каплау планлаштырыла торган инвестиция проекты кысаларында булдырылган (төзелгән) йә реконструкцияләнгән күчемсез мөлкәт объектларына һәм линия объектларына технологик аудит уздыру тәртибе, күрсәтелгән аудитны үткәргән өчен түләү күләме, бу түләүне алу тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.» сүзләренә алмаштырырга;

**2 статья**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 5 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2025, № 18 (I өлеш), «$1^1$» саннарын төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «б» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «б» пунктчасы 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында әзерләнде.

«Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 4 ноябрендәге 413-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) Россия Федерациясендә капитал салуларны яклауга һәм кызыксындыруга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән. Федераль закон, шул исәптән, инвестиция проектын гамәлгә ашыручы оешмага чыгымнарны субсидия яисә түләнгән салымны кайтару рәвешендә каплауны күздә тота торган дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү тәртибен төгәлләштерүне күздә тота.

Шуңа бәйле рәвештә закон проектына капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектларына дәүләт ярдәме чараларын күрсәтүне регламентлаштыручы «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына, шулай ук «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 5 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына охшаш үзгәрешләр кертелә.

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.